

# ЧИШМӘ БАШЫ


Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

№1 2025ел
сентябрь


80 ЖИҢҮ!

***Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

- 1 сентябрь – Белем көне!
- 27 сентябрь- Тәрбиячеләр көне!
- Баланың бакчага ияләшү чоры
- Балаларны юлда йөрү һәм тормыш куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү
- Беслан

## 1 сентябрь – Белем көне!

1 сентябрь – Белем көне. Бу көнне без беренче кыңгырау, туган мәктәбебез, тугрылыклы сыйныфташларыбыз, олы йөрәкле укытучыларыбызны тагын бер кат искә төшерәбез. Белем көне – балачак хатирәсе булып һәрберебезнең күңел түрендә саклана торган көн ул. Иң матур кеше – белемгә омтылган кеше. Белемдә – бәхет, белемсезгә – дөнья ләхет, ди бит татар халык мәкале дә. Шуңа күрә һәрчак белемле булыйк, белемгә омтылыйк! Быел беренче мәртәбә парта артына утыручылар тырышып укысын, бетмәс-төкәнмәс белем хәзинәләрен ачсын. Кайгыртучан укытучыларыбызга изге эшләрендә уңышлар һәм сабырлык юлдаш булсын.

1980 еллар уртасына кадәр 1 сентябрь уку елының башлану көне булып кына саналган, ә бәйрәм буларак каралмаган. РСФСР мәктәбенең атказанган укытучысы Федорховецкий аны бәйрәмгә әверелдерергә һәм мәктәп укучылары өчен тантаналы чаралар оештырырга тәкъдим итә. 1984 елның 15 июнендә ССРБ Югары Советы Президиумы «Бәйрәм һәм истәлекле көннәр турында» указ чыгара һәм 1 сентябрь бөтенхалык Белем көне дип игълан ителә. Шул вакыттан ССРБның барлык мәктәпләрендә дә 1 сентябрьны тантаналы чара белән билгеләп үтү гадәте барлыкка килә. Шул вакыттан ССРБның барлык мәктәпләрендә дә тантаналы чаралар оештырыла башлый, көннең беренче яртысы тематик дәресләргә һәм укытучылар белән очрашуларга багышлана. ССРБ таркалгач, традиция сакланып кала: 1 сентябрь Россиядә һәм постсовет киңлегенең күпчелек илләрендә бәйрәм һәм беренче уку көне булып санала.





# 27 сентябрь- Тәрбиячеләр көне!

Календарьда балалар көлүләре, яхшы сүзләр һәм ихлас рәхмәтләр белән тулы үзенчәлекле көн бар. Бу-27 сентябрь, Тәрбиячеләр һәм Россиянең барлык балалар бакчасындагы хезмәткәрләре көне. Көн саен мөмкин булмаганны эшләүчеләр бәйрәме: сабыйлар өчен икенче ата-ана булучылар бәйрәме!
Тәрбияче-педагогик белемле белгеч кенә түгел. Бу сирәк очрый торган сабырлык сәләте, эчке яктылыгы һәм һәр балада шәхесне күрү сәләте булган кеше. Нәкъ менә тәрбиячеләр дуслашырга, уртаклашырга, көчсезләрне рәнҗетмәскә һәм башкаларның хезмәтен хөрмәт итәргә өйрәтә. Мәктәпкәчә яшь-кеше үсешендә фундаменталь яшь — нәкъ менә шушы елларда характер нигезләре, үз-үзеңне тоту моделе, эмоциональ интеллект салына.
Бәйрәмнең тарихы 1863 елда — Санкт-Петербургта Россиядә беренче балалар бакчасы ачылу көненә барып тоташа. Аны педагог һәм мәгърифәтче Аделаида Семеновна Симонович төзегән. Ул балачак — олы тормышка әзерлек кенә түгел, ә махсус караш һәм кайгырту таләп итә торган кыйммәтле вакыт, дип санаган немец педагогы Фридрих Фребель идеяләре белән илһамланган. Рәсми бәйрәм көне 2004 елда гына булса да, ул инде гомерендә бер тапкыр булса да сабыйны кулыннан тоткан һәм аны балачак лабиринтлары аша алып барган һәркемнең йөрәгендә яши.

Кадерле тәрбиячеләр, педагоглар һәм балалар бакчасының барлык хезмәткәрләре! Сезнең игелегегез, кайгыртучанлыгыгыз һәм сизгерлегегез балалар күңелендә мәңгегә саклана. Яктылыгыгыз, җылыгыз, сабырлыгыгыз өчен рәхмәт сезгә. Сез-гомерлеккә истә кала торган балачак тудыручы тылсымчылар. Сезгә сәламәтлек, күңел тынычлыгы, энергия һәм бәхет телибез. Шуны истә тотыгыз: Сез җир йөзендәге иң мөһим эш белән шөгыльләнәсез!









# Баланың бакчага ияләшү чоры



Бакча – бала өчен әти-әни эштә чакта калып тору урыны гына түгел. Биредә ул яңа кешеләр белән танышырга, яшьтәшләре белән аралашырга өйрәнә, билгеле бер норма һәм кагыйдәләрне үзләштерә, җәмгыятьтә яшәргә яраклаша.

Баланы бакчага әзерләр алдыннан, ата-ана моңа үзе дә әзер булырга тиеш. Моның өчен бакчадагы режим белән танышырга, нинди дәресләр һәм уен чаралары булганлыгы белән кызыксынырга киңәш ителә. Булачак тәрбиячеләр белән танышу да комачау итмәс. Аларга баланың холык үзенчәлекләрен, гадәтләрен, нәрсәләр белән кызыксынуы хакында алдан ук хәбәр итеп куярга кирәк.

Бакчадагы шартлар үзгә: туклану, ял итү режимы да, тәрбия чаралары да. Шуңа күрә бакчага йөри башлагач та, баланың холкы үзгәрә башлый. Аның аппетиты кимергә, йокысы бозылырга мөмкин. Кайбер очракта сәбәпсез тән температурасы күтәрелә. Баланың эмоциональ кичерешләре аның организмының каршы торучанлыгын киметә. Шунлыктан адаптация чорында күп кенә балалар авырый башлый.

Адаптация чоры һәр балада төрлечә күзәтелә. Йә ул бик тиз ияләшә, йә ай буе еларга мөмкин. Бу яшь үзенчәлекләреннән дә торырга мөмкин. 10 айдан алып 1,8-2 яшькәчә булган балаларга адаптация аеруча авыр бирелә. Бу яшь аралыгында баланың гадәтләре формалаша башлый, ә аларны үзгәртеп коруга ул әле әзер түгел. Ә 2 яшьтән соң исә бу җиңелрәк бирелә. Балага бөтен нәрсә кызык булып тоела, аны яңа уенчыклар, уеннар белән кызыктырырга мөмкин. Икенче яктан, ул өлкәннәрнең ни сөйләгәнен дә яхшы аңлый. Шунлыктан аны тынычландыруы җиңелрәк.

Шунысы да бар: бер үк яшьтәге балалар төрле шартларга төрлечә ияләшә. Бу холык үзенчәлекләренә бәйле. Кайбер балалар кычкырып еларга, ашаудан баш тартырга мөмкин. Әмма ике-өч көн дә узмый, ул тынычлана, аппетиты, йокысы яхшыра, ул тәрбиячеләр һәм башка балалар белән теләп аралаша башлый.

Бакчага килгән беренче көннәрдән үк үзләрен тыныч тотучы балалар да бар. Алар тыныч кына утыра, аппетитсыз гына ашый, күзен йомган көе йокларга ята, әмма озак кына йокыга китә алмый. Уенчыкны кулына ала, әмма аның белән уйнамый. Ата-анасы килүгә исә, елый-елый, кочакка ташлана. Менә мондый балаларга карата игътибар аеруча зур булырга тиеш. Тышкы яктан тыныч булып, эчке яктан бастырылган мондый эмоциональ торыш бик озак дәвам итеп, авырып китүгә сәбәпче булырга мөмкин.

Баланың бакчадан кайткач, нинди шартларга килеп эләгүе дә адаптация чорына йогынты ясый. Вакытында ашау, йоклау кебек режим өйдә дә саклангса, балага күпкә җиңелрәк булачак. Баланы юынырга, киенергә, ашатырга өйрәтү дә зур әһәмияткә ия. Боларны эшли белмәү шулай ук авырып китү мөмкинлеген арттыра.









# Балаларны юлда йөрү һәм тормыш куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү



Соңгы елларда республикабызда автотранспорт саны, юлларда машина хәрәкәте көннән-көн арта бара. Шуның нәтиҗәсендә балаларның юл-транспорт һәлакәтенә юлыгу куркынычы да көчәя. Ә бу исә, үз чиратында, балаларга мәктәпкәчә яшьтән үк юл йөрү куркынычсызлыгы кагыйдәләрен өйрәтү кирәклегенә басым ясый.
Бала чакта алган белем һәм күнекмәләр яхшы үзләштерелә, тиз генә онытылмый, гомер буе саклана. Балаларга кечкенәдән үк "юл әлифбасын" өйрәтү, аларда юлда йөрү кагыйдәләрен формалаштыру - әти-әниләрнең, балалар бакчасы тәрбиячеләренең, барлык педагогларның изге бурычы.
Кызганычка каршы, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү буенча балалар бакчасында алып барылган эш гаиләдә ныгытылмый. Нәтиҗәдә балаларның белеме очраклы факторларга бәйле була. Балалар катнашындагы юл- транспорт һәлакәтен олылар очраклы хәл дип бәялиләр. Ләкин юл-транспорт һәлакәтен билгеле ялгышлар, тәҗрибәсезлек, күреп бетермәгәнлек, дөрес карар кабул итә белмәгәнлек күренеше дип карарга кирәк.
Балаларны юлдагы күңелсез хәлләрдән ничек сакларга? Балаларны без ничек кенә өйрәтсәк тә, тормышта алар олыларның эшен кабатлыйлар. Юл аркылы тиешсез урыннан чыккан өчен баланы ачуланганчы, иң башта сез үзеннән сорагыз. Һичшиксез ул сезгә ничек олы кешенең тиешсез урыннан юл аркылы чыкканын күрүе турында сөйләячәк. Бала күзлегеннән караганда әти-әнисе эшләгәннән дә яхшырак эш булмый. Әти-әниләр бала өчен үрнәк булып торалар. Әти-әниләр юлда булганда шуны истә тотсыннар иде.

**Мәктәпкәчә яшьтәге бала түбәндәгеләрне үзләштерергә тиеш:**

- юл йөрү кагыйдәләрен;
- юл элементларын (юл, машина юлы, тротуар, юл кырые, җәяүлеләр юлы, чат);
- транспорт төрләрен (трамвай, автобус, троллейбус, җиңел машина, йөк машинасы, мотоцикл, велосипед);
- юл йөрүне көйләү чараларын;
- светофор сигналларын: кызыл, сары һәм яшел;
- юл кырыеннан һәм тротуардан йөрү кагыйдәләрен;
- машина юлын аркылып чыгу кагыйдәләрен;
- олылардан башка юлга чыгарга ярамый;
- җәмәгать транспортына утыру, аннан чыгу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре





**Моның өчен түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:**

1. Үзләштерергә кирәк булган кагыйдәләр белән генә таныштыру;
2. Үзләштерү өчен ишегалдында, юлда прогулка вакытындагы ситуацияләрне куллану;
3. Юлда нәрсә булганны аңлатырга, нинди транспорт чараларын күрүен ачыкларга;
4. Кайчан һәм кайда юлны аркылырга ярый, кайда ярамый;
5. Кагыйдәләрне бозган җәяүлеләрне яки машина йөртүчеләрне күрсәтү;
6. Баланы велосипедта йөрү кагыйдәләренә өйрәтү (кайда йөрергә ярый, кайда ярамый, борылганда һәм туктаганда ничек сигнал бирергә);
7. Бала белән бергә велосипедта йөргәндә, аны карап хаталарын кисәтеп бару өчен, артыннан барыгыз;
8. Күрү хәтерен ныгыту (транспорт чарасы кайда, юл элементлары, кибетләр, мәктәпләр, балалар бакчалары, даруханәләр, җәяүле юллары, светофорлар);
9. Пространство күзаллауларын үстерү (якын, ерак, сулда, уңда, хәрәкәт буйлап, артта);
10. Транспорт чаралары, җәяүлеләрнең тизлеге турында күзаллауларны үстерү (тиз йөри,әкрен,борыла);
11. Баланы урам белән куркытмаска;
12. Балаларга юл йөрү куркынычсызлыгы турында шигырьләр, табышмаклар, китаплар укырга.







# Беслан

3 сентябрьдә безнең балалар бакчасы балалары Беслан шәһәрендәге фаҗигагә багышланган "Тормыш тамчысы" Бөтенроссия акциясенә кушылдылар. Балалар пөхтә итеп учларына су җыеп, чәчәкләргә су сибәләр, бу фаҗига вакытында балаларның эчәргә теләвен күрсәтә иде. Бу гади, ләкин тирән мәгънәле ишарә барыбызга да, бигрәк тә авыр вакытларда, бер-беребезгә ярдәм итү һәм кайгыртуның мөһимлеген искә төшерде. Балаларны коткару мөмкинлегенә балалар зур хөрмәт һәм аңлау белән карадылар, үз кайгыларын һәм кызгануларын белдерделәр.
Без чын күңелдән ышанабыз, мондый фаҗига беркайчан да кабатланмаячак, һәм безнең планетадагы барлык балалар тынычлыкта һәм куркынычсызлыкта үсәчәк.














*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*